РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
СОВЕТ ТИМБАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТИМБАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

« 24 » ноябрь 2016ел № 22-1

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының
Тимбай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт
турында 2016 елның 7 сентябрендәге 16-1 номерлы
Тимбай авыл җирлеге Советы карары белән
расланган нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Буа муниципаль районы Тимбай авыл җирлеге Уставы нигезендә, Буа муниципаль районы Тимбай авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Тимбай авыл җирлеге Советының 2016 елның 7 сентябрендәге 16-1 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль районының Тимбай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 бүлекне үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә :

« 6 бүлек. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү буенча квалификация таләпләре

6.1. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына, вазыйфаи бурычларны башкару өчен кирәкле белемнәргә һәм күнекмәләргә, шулай ук яллаучы (эш бирүче) вәкиленең тиешле карары булганда - белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләренә туры килү таләп ителә.

6.2. Һөнәри белем бирү дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт стажына яисә муниципаль хезмәт Вазыйфаларын биләү өчен кирәкле белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләре әлеге бүлекнең 6.3 пунктында билгеләнгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен типлаштырылган квалификация таләпләре нигезендә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә. Вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләре, муниципаль хезмәткәрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә карап, аның вазыйфаи инструкциясе белән билгеләнә. Муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясе шулай ук белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләре дә каралырга мөмкин.

6.3. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге типлаштырылган квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә: вазыйфаларның югары, төп һәм әйдәүче төркемнәре өчен югары белем булу; вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен югары белем яисә урта һөнәри белем булу;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча - кимендә ике ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә биш ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча - кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфалары буенча - кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы.

6.4. Өлкән һәм кече төркемнәр муниципаль хезмәте Вазыйфаларын биләү өчен муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләре билгеләнми.».

2. Әлеге карар имзалау мизгеленнән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatrstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

ТР Буа муниципаль районы Тимбай
авыл җирлеге башлыгы, ТР Буа муниципаль
районы Тимбай авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Р. Вәлеев